ФОМА УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ МӘКТӘБЕ УКУЧЫЛАРЫНЫҢ АЙЛЫК ГАЗЕТАСЫ

# «КӨЗГЕ»

КӨЗГЕ

май
2018 нче ел

№9(39)

**ҮЗЕҢ НИНДИ, КӨЗГЕҢ ШУНДЫЙ!!!**






**1 май—Яз һәм хезмәт бәйрәме**

**9 май— Җиңү көне**

**19 май –Балачак бәйрәме**

**24 май –Соңгы кыңгырау**

Көн саен үзенең хезмәте белән Ватанын һәм гаиләсен чәчәк аттыручы бөтен халык бәйрәме. Өлкән буын өчен 1 Май элеккечә пролетар бердәмлекне гәүдәләндерә, ә яшьләр өчен –табигать һәм кешелек көчен тудырган язгы чәчәк ату чоры.

1 Май бәйрәме беренче тапкыр 1890 елда Варшавада, ә 1891 елда Санкт-Петербургта бәйрәм ителә.

Бәйрәм тарих төсмерен саклап калып, бүген дә бөтен кешелек дөньясы өчен элеккеге кебек үк хезмәт ияләре бәйрәме, хезмәт, тынычлык, үзара татулык бәйрәме булып кала. Ни генә булмасын, 1 май чын-чынлап яз килүен белдерә. Нәкъ менә бу айда алмагачлар, шомыртлар ап-ак чәчкәгә күмелә. Бар җиһан гүя әкияти дөньяны хәтерләтә.

Барыгызны да яшел чирәмнәре шытып чыккан, каеннары яфрак ярган яз бәйрәме белән котлыйбыз. Яз сулышы күңелегезгә нур өстәсен. Бәхет кояшы көннән-көн яктыра барсын, йөрәгегез хискә тулсын, һәрвакыт яшь булсын. Гомерегез дә яз көне кебек якты, кояшлы, аяз күкле, нурлы булсын.

**Бу санда:**

| | |
|---|---|
| Май бәйрәме | 1 |
| Тормышчан әкият | 2 |
| Конкурслар | 3 |
| Бәйрәмнәр | 4 |
| Якыннан танышыйк | 5 |
| Котлыйбыз | 6 |

## Укучыбыз иҗаты «Ялкын» журналында

# Кәҗә, сарык ничек исән калган? (*тормышчан әкият*)

Борын-борын заманда түгел,
Узган гасырда гына,
Сиксәненче елларында
Хикмәтле вакыйга була.
Кәҗә - командир, саескан – сотник,
Үрдәк урядник түгел,
Ә менә яшел урманда
Санитар булган бүре.
Шул чорда минем әбием
Булган бары тик әни,
Ә газиз әти-әнием
Булганнар әле бәби.
Нурлы Нурлат урманында
Җәйге бер матур көндә
Ике бүре йөри икән
Җыючы булып гөмбә.
Буш кәрзин тотып, бик озак
Урман буйлап йөргәннәр,
“Файдасыз уздырдык көнне”, -
Шул фикергә килгәннәр.
Болар шулай аптырашып
Утыралар уй уйлап.
Нәкъ шул чакта күзләренә

Кисмәк чалына ялтырап.

Якынрак килеп баксалар,
Бер түгел, икәү икән.
Кисмәк дигәне тимердән,
Кызыл төстә, дәү икән.
Әйтә икән кечерәк бүре:
Монда нинди хикмәт бар?
Эче дә буш түгел кебек,
Мөгаен, алтын-мазар!
Алай борып карыйлар,
Болай тотып карыйлар,
Кояш батып, кич җиткәнче,
Серен чишә алмыйлар.
Кызыксынулары көчле -
Төн җитү дә туктатмый.
Олы бүре шырпы сыза,
Һәм шулчак нидер шартлый!..
Рәт-рәт тезелеп утырган
Агачларга ут каба.
Шатыр-шытыр, чырт-чырт итеп,
Ямь-яшел урман яна.

Ходайның хикмәте белән
Башлана шул мәл яңгыр!
Чиләкләп коя урманга,
Юкса аннан ни калыр?

Иртән генә явып туктый,
Урман янмый, ни гаҗәп?!
Тик ике бүредән бары
Бер баш кала тәгәрәп...
...Икенче көн бу урманга
Килгән, ди, кәҗә, сарык.
Утлап йөри бу хайваннар,
Эзләгәннәр, ди, азык.
Башын иеп бара торгач,
Сарык бүре башы күрсә,
Кәҗә ерак түгел җирдә
Таба әллә нинди нәрсә.
“Син тот”, “Син бор!” – бәхәсләшә,
Аннан икәү киңәшләшә,
Бүре башын бер капчыкка
Бергә салырга килешә.
Кызыл савыт нигә хаҗәт?
Белә алмый интегәләр.
Эчендә бөртек булыр дип,
Ачмак булып мәш киләләр.
Ярый әле килеп чыга
Бу урманның хуҗасы.
Вакытында килми калса,
Тагын мәхшәр буласы.
Тәҗрибәле Шүрәленең

Сүзләре катгый була:
“Һәр ялтыраган нәрсә
Әллә соң алтын була?!
Ят әйбергә кагылмыйлар,
Һәрчак сак булу кирәк!
Әлбәттә, бу газ баллоны -
Тормышыбызда терәк.
Әмма дөрес кулланмасаң,
Зур бәлага тарыйсың,
Газ булган урында куллан
Бар саклану чарасын!”
Кәҗә, сарык куркып киткән,
Аннан чиксез шатланган,
Чөнки бүген аларны
Шүрәле бит коткарган!

Бу урманга газ баллоны
Ничек килеп чыккан соң?
Ә берсе нигә шартлаган,
Бусын кайда куясын –
Барысын да тикшерергә,
Чараларын күрергә
Чакырганнар газчыларны
Әлеге урман түренә.
Кәҗә, сарык бит ул чакта
Берни белмәгән икән.

Баллондагы газ белән
Плитә эшләгән икән.
Шуңа һәрбер өйдә пешкән
Тәмле аш, бәлеш, дүрчмак,
Кыстыбый, пилмән һәм белен,
Тутырма, чәй, өчпочмак...
Инде ул заманнан бирле
Бик күп нәрсә үзгәрде:
Плитәгә генә түгел,
Мичләргә газ эленде.
Бер шырпы белән кабызып,
Кышны чыга һәр кеше,
Тормыш күпкә җиңеләйде,
Беткән күк булды эше.
Утын кисми, брикет кертми,
Ташкүмер дә ватмыйбыз,
Исәплəгеч искәртә дә
Газга акча саныйбыз.
Безгә кала онытмаска
Вакытында түләүне,
Зәңгәр ягулык булган газ -
Хәзинә, табигать бүләге.
Газ ул –яшәү чыганагы,
Газ бар җирдә тормыш бар.
Сакчыл булыйк, кадерен белик,

Газ булганда ил дә бай!

**Хисматова Зәринә**, ТР Нурлат муниципаль районы МБГБУ “Фома урта гомуми белем мәктәбе”нең 6 нчы сыйныф укучысы.

**«Ялкын» журналы һәм «Газпром трансгаз Казан» сезне чираттагы бәйгедә катнашырга чакыра. «Яшәү чыганагы – газ» дип аталган конкурста мәктәп укучылары да, студентлар да катнашырга мөмкин. Әлбәттә, әти-әниләр, укытучылар белән бергәлектә эшләү хуплана.** (материал «Ялкын» журналыннан алынды)

# Конкурслар



**Узган ял көне (13 май 2018 ел) безнең мәктәп укучылары өчен аеруча файдалы һәм күңелле узды. Без башкалабыз Казанны “алдык”.**

“Тамчы-шоу” интеллектуаль күңел ачу уенында катнашучылар һәм аларның җанатарлары җитәкче укытучыларыбыз белән сәяхәтебезне иң элек Бауман урамыннан башладык. Аннары Кремльдә булдык, Кол Шәриф мәчетенә кердек, Сөембикә манарасын якыннан барып карадык. Биеклектән Казаныбыз уч төбендәге кебек күренә икән. Безнең хис-кичерешләребезне сөйләп бетерерлек түгел. сөйләп бетерерлек түгел.

Аннары билгеләнгән вакытка ТНВ каналы бинасына бардык. Катнашучыларның берсе үземнең туган абыем да булгач, тагын да дулкынландым. Безнең көндәшләр Биектау районы Мүлмә мәктәбенең “Ялкын” командасы кызлары да бик көчле, акыллылар иде. Ләкин уен булгач, анда җиңүче дә, оттыручы да була. Әмма, минемчә, бу уенда катнашу да җиңүгә тиң.

Шулай да олы бәхет “Нурлы як йолдызлары” командасына елмайды. Зарипова Зилә, Хисматов Рәсим, Гомәрова Ләйсән өстәмә баллар да ала торгач, исәп 25-26 булды. Безнең мәктәп, район данын лаеклы яклап кайта алуыбыз күңелләрдә горурлык хисләре уятты. Әбием, уенга әзерлек барышында үзенә ярдәм иткәнем өчен рәхмәт әйткәч, иңнәремә канатлар үсте.

лар иде. Ләкин уен булгач, анда җиңүче дә, оттыручы да була. Әмма, минемчә, бу уенда катнашу да җиңүгә тиң.

Шулай да олы бәхет “Нурлы як йолдызлары” командасына елмайды. Зарипова Зилә, Хисматов Рәсим, Гомәрова Ләйсән өстәмә баллар да ала торгач, исәп 25-26 булды. Безнең мәктәп, район данын лаеклы яклап кайта алуыбыз күңелләрдә горурлык хисләре уятты. Әбием, уенга әзерлек барышында үзенә ярдәм иткәнем өчен рәхмәт әйткәч, иңнәремә канатлар үсте. **ЗӘРИНӘ.**





2017 –2018 нче уку елы дәверендә Фома урта мәктәбе укучылары үзләрен барлык яктан да булган итеп күрсәттеләр. Бик күп чараларга катнашып, конкурсларда җиңүче булдылар. Алай да иң куанычлысы олимпиада нәтиҗәләре булды. Елдагыча быел да укытучылары Әһлиуллина Гөлүсә Дамир кызы җитәкчелегендә Зарипова Зилә (7 нче сыйныф), Гайсина Гөлшат (9 нчы сыйныф), Гафурова Алия (10 нчы сыйныф) татар теленнән призлы урыннарга лаек булып, 10нчы май көнне сәләтле укучылар слетында бүләкләнделәр. Әфәрин, кызлар!!!




Май ае мәктәбебез өчен чараларга бик бай булды. Рамазан ае башлану сәбәпле Кизләү культура йортында республика буенча балалар өчен Әхмәдзәки хәзрәт Сафиуллин истәлегенә багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция уздырылды. Мәктәбебез укучылыры: Әһлиуллина Әлинә, Хайбуллин Айдар, Вәгыйзова Әлинә, Әһлиуллин Аяз, Хайбуллина Алсу, Гафурова Алия, Шакурова Алсу дини белемнәребез белән үз чордашларыбыз арасында матур гына чыгыш ясадык һәм дипломнар белән бүләкләндек. Бу очрашу күңелләребезгә нур өстенә нур өстәде. *Гафурова Алия*

## 9 май—Җиңү көне.

Быел Бөек Җиңүгә 73 ел тулды. 9 нчы май көнне һава торышы да бик матур иде. Фома авылы җирлегендә ике сугыш ветераны бар. Алар: Каняфин Исхак һәм Шәйхетдинов Рәхим бабайлар. Бүгенге көндә алар балаларында гомер итәләр. Бәйрәмгә кайта алмадылар. Шуңа карамастан авыл хылкы, тыл ветераннары бәйрәмгә җыелган иде.







Кичәне авылның мулласы Фахреев Рифкать Бәдретдин улы дога белән ачып җибәрде. Авыл җирлеге башлыгы Абрахманов Рәшит һади улы һәм килгән кунаклар халыкны бәйрәм белән котладылар. Һәйкәлгә веноклар куелды.

Бәйрәм кичәсе бар халыкның күңеленә хуш килде.

*Аглетдинова Гөлләр*






## 24 май— “Соңгы кыңгырау “ бәйрәме

с последним звонком




2017-2018 нче уку елының 11 нче сыйныфын 5 укучы: Гайсин Илшат, Вәгыйзова Ләйсән,Фәйзетдинова Алсу, Әһлиуллина Әлинә, Хайруллин Булат тәмамладылар. Бу балалар үзләрен бары тик тырыш, тәртипле итеп күрсәттеләр, яхшы укыдылар. Сыйфат та, өлгереш тә 100% иде аларның. Сыйныф җитәкчеләре, математика фәне укытучысы Сөләйманова Раилә Заһид кызы укучыларын олы юлга бар тәҗрибәсен куеп әзерләде. Аларга зур уңышлар телибез!



Я смутно помню свой первый «первый сентябрь».
Совсем ещё маленькая, но бойкая я,
Чувствовала себя, как уплывающий в море корабль.
Я шагала уверенно всегда
По широким коридорам, как казалось мне тогда,
Моя первая учительница, с доброй душой
Спасибо, что были опорой!
Моя классная, человек для нас всех дорогой,
Спасибо, что окружили заботой! ...

*Аглиуллина Алина*

# Якыннан танышыйк!



«Яшь журналистлар» төркеме

Фома урта мәктәбе ветеран укытучысы Измайлова Роза Шарафулла кызы белән очрашуда булып кайтты.

- Роза апа, сез ничәнче елда, ничә яшегездә Фома авылына ни сәбәпле килдегез?

- 1966 нчы елда 21 яшемдә Казаннан юллама буенча мәктәпкә укытырга килдем. РОНО да мине чуваш авылына җибәрергә тиеш булсалар да, татар кызы икәнемне белгәч татар авылына эшкә билгеләделәр. Ул вакытта Фомда яңа мәктәп ачылган гына иде әле. Ул сигезьеллыктан тугызъеллыкка әйләнде. Ремонт эшләре бетмәгән дә иде әле. Озакламый ул 10 еллык булды.

-Ә үзегез кайсы якныкы?

- Буа районы Суыксу авылыннан.

- Мәктәптә сез нинди фән укыттыгыз?

- Гомерем буе математика укыттым, чөнки профессиям буенча мин математик. Курслар тәмамлап информатика да укытырга туры килде 1-2 ел.

- Сез мәктәптә эшләгән вакытта балалар күп идеме?

- Искиткеч күп иде. 33-40 бала һәр класс саен. Икегә бүләләр иде. Күрше Биккол, Зирекле, Илюткино авылларыннан да балалар 9-10 классларга укырга йөрде. Тәртипле иде ул заман балалары, тырышып укый иделәр.

- Мәктәптә эшләү чорларын нинди хисләр белән искә аласыз?

- Алар гел төшкә керә. Дәрес алып барулар, истән чыкмый бер дә. Балалар белән колхоз эшеннән кайтмый идек. Салам яндыру, чөгендер үстерү,суган үстерә идек күп итеп.Физик хезмәт күп иде безнең чорда.

- Сез Равил абый белән ничә бала тәрбияләдегез, хәзер алар кайда?

- Без 3 бала тәрбияләп үстердек. Алар тормышта бар да үз урынын тапты. Һәркайсы яраткан һөнәрләре белән шөгыльләнәләр аллага шөкер.

-Роза апа, бүгенгесе көндә сез үзегезне ялгыз хис итмисезме?

- Бик уңайсыз, үземне ялгыз хис итәм. Дәрес бергә эшләгән Нәгыймә апагыз, Рәзинә апагыз киләләр.Балалар кайта. Алай да ялгызлык беркемгә дә язмасын иде.

- Әңгәмәгез өчен зур рәхмәт.

- Сезгә дә зур уңышлар телим.

## Без «Ялкын» журналының даими җиңүчеләре




**Мәктәп белән флешмоб биедек**

Безнең мәктәптә сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау максатыннан бик күп төрле чаралар оештырылып тора. Алар төрле форматта, төрле вакытта уздырылуларына карамастан, барысы да безне спорт белән шөгыльләнергә чакыра. Ә менә күптән түгел үткәрелгәне укучылар күңеленә аеруча хуш килде.

Ул иртәдә мәктәп эченә керергә ашкынып торучылар булмады, чөнки язгы саф һаваны сулап, мәктәп каршына тезелеп басып, олысы-кечесе флешмоб биергә әзерләнгән. Дәртле музыка астында барың бер төрле хәрәкәтләнү кызык та, күңелле дә, шул ук вакытта җаваплы да икән. Район мәгариф бүлегеннән чыккан Гөлүсә Фоадовнадан әлеге чараны нинди ният белән оештыруы хакында сорадым. “Мәктәптә һәр иртәне зарядкадан башлыйбыз бит. Ә аны менә шулай тагын да күңеллерәк уздырып була. Укучылар хәрәкәттә - бәрәкәт булуын, кумәкләшеп эшләү никадәр җиңеллек китерсә, бергәләшеп ял итү дә күпкә куанычлырак икәнлеген аңлаганнардыр, мөгаен”,- диде ул елмаеп. Соңыннан флешмобта катнашучыларның да фикерләрен белешергә булдым. Сыйныфташым Алинә: “Бу бию безне берләштерде, тагын да якынайтты”,- ди. Рузиләбез исә мәктәпнең барлык укучыларын үз артыннан биюне кабатлата алуына чиксез куанган. Башлангычлар да берсен-берсе бүлә-бүлә аның иң оста биюче булуын хуплады. Бишенчеләрнең дә авызлары колакта: “Шундый рәхәт, шундый күңелле!”-диләр. Аннары башлангычлар “Күңелле старт” ярышына, ә калганнар беренче дәрес булып үтә торган тәрбия сәгатьләренә таралыштык. Сәламәтлек темасына багышланган дәрестән чыкканда, һәркемнең күңелендә сөенеч һәм зур максатлар булгандыр, мөгаен. Сөенәбез, чөнки без сәламәт, ә шул сәламәтлекне саклау, ныгыту безнең бурыч икәнлеген тагын бер кат аңладык бүген.

**Аяз Әһлиуллин, Нурлат, Фома мәктәбе.**

(**“Ялкын” журналының апрель ае** санынннан алынды)




Май аенда туучы

кадерле укучыларыбыз!

**Аглетдинова Гөлләр, Мокина Яна, Аглетдинова Гөлләр, Вилданов Рәзил, Закирова Диана, Галимова Инзилә, Хайбуллина Фатыма!**

**Сезнең барыгызны да чын күңелебездән туган көнегез белән тәбрик итәбез. Сезгә укуыгызда зур уңышлар, нык сәламәтлек телибез.**

**Озын булсын гомерегез,**
**Тыныч булсын күңелегез.**
**Бәхет чишмәләрегез мул аксын,**
**Зур шатлыклар белән таң атсын!**

**Бу сан өчен мәктәпнең «Яшь журналист» түгәрәге әгъзалары җаваплы**

**“ К Ө З Г Е ”**

**Директор:** Сафиуллин Хәлим Салихович

***“Фома урта гомуми белем мәктәбе”*** тарафыннан гамәлгә куелды.

(423012 Нурлат районы, Фома авылы, Мәктәп урамы, 18)

Газетага нигез салынды: сентябрь, 2011

Газета уку вакытларында айга бер тапкыр чыга.

Тиражы *чикләнмәгән.*

**Баш мөхәррир**: Фәхретдинова Равидә Нәгыймовна

**Урынбасары:** Әһлиуллин Аяз Илфат улы

**Дизайнер**: Гафурова Алия

**Корректор**: Әһлиуллина Гөлүсә Дамировна

**Редколлегия**: Әһлетдинова Гөлләр, Гайнуллина Алия, Гайсина Вероника, Закирова Гөлинә, Масгутова Гөлназ, Хайруллина Әдилә, Хисматова Зәринә